КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 10 ноябрь г.Казань № 859

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе мәсьәләләре» 2012 ел, 10 март, 202 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе мәсьәләләре» 2012 ел, 10 март, 202 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 13 октябрь, 852 нче; 2013 ел, 18 март, 176 нчы; 2013 ел, 31 октябрь, 829 нчы; 2014 ел, 18 апрель, 257 нче; 2014 ел, 10 июль, 481 нче; 2015 ел, 21 гыйнвар, 25 нче; 2016 ел, 26 июль, 508 нче; 2016 ел, 19 август, 575 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пункттагы «348,9» саннарын «358,3» саннарына алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе турындагы нигезләмәдә:

3 нче бүлектә:

3.2 нче пунктта:

алтынчы абзацтагы «Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе» дигән сүзләрне «Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты» дигән сүзләргә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норматив документлар эшләү эшчәнлеген яраштыру (шул исәптән Татарстан Республикасы

норматив хокук актлары проектларының федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килү-килмәвен тикшерүдә тоту) (02.04.01<*>);

республика башкарма хакимияте органнарының норматив хокук актларын дәүләт теркәве (02.04.03<*>).»;

3.3 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле 3.3.26 нчы пунктча өстәргә:

«3.3.26. Татарстан Республикасы территориясендә файдаланылмый торган үләт базларын (биотермик чокырларны) бетерү чараларын үткәрүне оештыруны гамәлгә ашыра, шул исәптән:

файдаланылмый торган үләт базларын (биотермик чокырларны) ветеринария-санитария тикшерүне үткәрү;

файдаланылмый торган һәм бетерелергә тиешле үләт базлары (биотермик чокырлар) исемлеген Баш ветеринария идарәсенең хокукый акты белән раслана торган тәртиптә формалаштыру;

файдаланылмый торган үләт базларын (биотермик чокырларны) бетерү.».

Татарстан Республикасы<br>
Премьер-министры | А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\859.docx